| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>ПРЕЗИДЕНТА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ПРЕЗИДЕНТЫ<br>**УКАЗЫ** |

**2021–2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерүнең төп юнәлешләре турында**

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының «2019–2021 елларга Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтен үстерүнең төп юнәлешләре турында» 2019 елның 24 июнендәге 288 номерлы Указы нигезләмәләрен исәпкә алып, киләчәктә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерү һәм аның кадрлар составына идарәне камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. 2021–2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерүнең төп юнәлешләре дип түбәндәгеләрне билгеләргә:

а) Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте (алга таба шулай ук – дәүләт хезмәте) вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучыларны сайлап алу тәртибен, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – дәүләт хезмәткәрләре) дәүләт хезмәтендә биләгән вазыйфаларына лаеклы булу-булмавын билгеләү тәртибен камилләштерү, шул исәптән:

дәүләт хезмәтенә кергәндә мәҗбүри гамәл буларак тест уздыруны файдалану;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучыларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын, дәүләт хезмәте вазыйфалары категорияләре һәм төркемнәрен исәпкә алып, аларның дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүгә куелган тиешле квалификация таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүнең яңа алымнарын эшләү һәм куллануга кертү;

дәүләт хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән затларның вазыйфаи үсешен тәэмин итү;

персоналга идарә итүнең заманча алымнарын исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт органнарының (алга таба – дәүләт органнары) кадрлар бүлекчәләре хезмәткәрләренең һөнәри компетенцияләрен үстерү;

дәүләт хезмәткәрләрен аттестацияләүнең нәтиҗәле механизмнарын үстерү;

б) Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатларын исәпкә алып, дәүләт хезмәткәрләрен һөнәри яктан өзлексез үстерү, шул исәптән:

заманча белем бирү инфраструктурасы булган алдынгы уку-укыту үзәкләрен эшкә җәлеп итеп, дәүләт хезмәткәрләренең цифрлы технологияләр, аналитика, тел өлкәләрендәге, тармакара һәм башка юнәлештәге белемнәрен комплекслы үстерү;

дәүләт хезмәткәрләрен укыту өчен мәгълүмати-мәгариф платформасын гамәлгә кертү;

дәүләт хезмәткәрләре өчен гамәлгә ашырылучы мәгариф программаларының сыйфатын бәяләүнең яңа ысулларын куллануга кертү;

в) дәүләт органнарында хезмәт культурасын камилләштерү һәм һөнәри яктан үсешкә омтылган яшьләрне дәүләт хезмәтенә җәлеп итү өчен шартлар булдыру һәм дәүләт хезмәтендә югары квалификацияле белгечләрне саклап калу, шул исәптән:

тәүге тапкыр дәүләт хезмәтенә урнашучыларга мөнәсәбәтле рәвештә хезмәт урынында җайлашу һәм остазлык технологияләрен актив куллану, дәвамчанлык принциплары нигезендә кадрлар составының тотрыклылыгын тәэмин итү;

дәүләт хезмәтен популярлаштыруда һәм аның абруен арттыруда заманча мәгълүмат-коммуникация платформаларын файдалану;

дәүләт органнарының кадрлар резервларын формалаштырганда, шулай ук дәүләт органнарында студентлар практика, стажировка узганда, дәүләт органнарының мәгариф оешмалары һәм яшьләр оешмалары белән хезмәттәшлеген тәэмин итү;

г) дәүләт органнарында оптимальләштерүне һәм кадрлар составына бердәм идарәне тәэмин итүдә мәгълүмат технологияләрен файдалану, шул исәптән:

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәй мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын башка мәгълүмат системалары белән берләштерү;

дәүләт органнарында кадрлар белән бәйле документларның электрон әйләнешенә этаплап күчүне тәэмин итү;

мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләр, тыюлар һәм таләпләрне, шулай ук һөнәри хезмәт этикасы һәм дәүләт хезмәткәрләре хезмәт тәртибенең гомуми принципларын үтәмәү очракларын ачыклау өчен мәгълүмат системаларын эшләү һәм гамәлгә кертү.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

әлеге Указның 1 пункты нигезендә билгеләнгән 2021–2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерүнең төп

юнәлешләрен исәпкә алып, 60 көн эчендә «2014–2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертергә;

әлеге Указны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәтне үстерүгә юнәлтелгән чараларны оештырганда әлеге Указның 1 пункты нигезендә билгеләнгән 2021–2023 елларга Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерүнең төп юнәлешләрен исәпкә алуны тәкъдим итәргә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 21 май
№ ПУ-398